**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

20.12.2018 Балык Бистәсе штп. № 284пи

2018 елга гражданнар керемменең максималь күләмнәрен һәм салым салынырга тиешле мөлкәт бәясен билгеләү турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 14 маддәсе, 91.3 маддәсенең 2 өлешенә, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге №131-ФЗ номерлы Федераль законның 1 өлешенең 6 пункты, 14 маддәнең 3,4 өлешләренә,2004 елның 28 июлендәге "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 өлешенең 6 пунктына, 15 маддәнең 3,5 өлешләренә, 2015 елның 16 мартындагы "Социаль файдаланудагы торак фондының торак биналарын наем шартнамәләре буенча торак биналар бирүдә гражданнарның хокукларын тормышка ашыру турында" 13-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законына, гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең максималь күләмен һәм гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче граждан милкендәге салым салынырга тиешле мөлкәтнең бәясен билгеләү (күрсәтелгән законга кушымтада бәян ителгән) Методикасына туры китереп, шулай ук Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставының 46 маддәсенә таянып, КАРАР БИРӘМ:

1. Социаль файдаланудагы торак фондының торак биналарын наем шартнамәләре буенча гражданнарның торак биналар бирүгә мохтаҗлыгын тану турында карар кабул итү өчен гражданнар кеременең максималь күләмнәрен һәм салым салынырга тиешле мөлкәт бәясен 2018 елга түбәндәгечә билгеләргә:

1.1) гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче граждан милкендәге салым салынырга тиешле мөлкәт бәясенең максималь күләме:

ялгыз яшәүче граждан өчен – 1 442 826 сум;
ике кешелек гаилә өчен – 1 836 324 сум;
өч кешелек гаилә өчен – 2 360 988 сум;
дүрт кешелек гаилә өчен – 3 147 984 сум;
биш кешелек гаилә өчен – 3 934 980 сум;
алты кешелек гаилә өчен – 4 721 976 сум;
җиде кешелек гаилә өчен – 5 508 972сум;

1.2) гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган уртача айлык берләштерелгән керемнең максималь күләме:

ялгыз яшәүче граждан өчен – 25 408,3 сум;

ике кешелек гаилә өчен – 16 168,9сум;

өч һәм аннан артык кешедән торган гаилә өчен – 13 859,1 сум.

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы бүлегенә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы авыл җирлекләре территорияләрендә социаль файдаланудагы торак фондының торак биналарын наем шартнамәләре буенча гражданнарны торак биналар бирүгә мохтаҗлар сыйфатында исәпкә куйганда әлеге карарның 1.1 һәм 1.2 пунктчаларында күрсәтелгән максималь күләмнәрне файдаланырга.

3. Әлеге карар көченең 2018 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә таралуын билгеләргә.

4.Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

5. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктураны үстерү буенча урынбасары Д.Н.Ризаевка йөкләргә.

Җитәкче Р.Л. Исланов